РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
20.10.2022

КАРАР
№22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының
депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм
муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 №881 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, № 10 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» гә таянып, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»не 28.04.2018 № 10 карары белән билгеләнгән

тәртиптә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфа окладлары күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәплләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 28.04.2018 № 10 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә” (Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 09.11.2020елгы №10 карары редакциясендэ) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 11 958 сум күләмендә расларга.»;

4.2.1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

6. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермәавыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А. И.Биккинин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль
районы Иске Икшермә
авыл җирлеге Советының
2022 елның 20 октябре, №22 карарына

Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 16390 |
| Депутатлар | 11958 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11958 |